# Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар» (Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 22 (674) 28 ноябрь 2018 ел (1440, Рабигуль-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Җәннәт – әниләрнең аяк астында



«Раббыгыз сезгә бары тик Аңа гыйбадәт кылуны һәм ата-аналарыгызга яхшы мөнәсәбәттә булуыгызны боерды. Әгәр дә аларның берсе яисә икесе дә картайса, аларга «Уф» дип тә әйтмә. Аларга тавышыңны күтәрмә, олылау белән дәш, кече күңеллелек канатларын җәй. «Раббым, аларга мәрхәмәтле бул, алар мине кече вакыттан тәрбияләделәр», – дип дога кыл». ( «Исра» сүрәсе, 23-24нче аять)

Бервакыт Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына бер кеше килеп: «Әниемә нинди хөрмәт күрсәтсәм, аның ризалыгына ирешермен дә, аның алдында булган бурычымны үтәрмен икән?» – дип сорый. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Әгәр әниеңне кулыңа күтәргән килеш Мәдинәдән Мәккәгә барып, хаҗ гыйбадәте үтәсәң дә, бу әниеңнең сине тапкандагы бер тулгагына да тормый», – ди. Ягъни әти-әни каршындагы бурычыбыз олы, алар безнең ахирәт сәгадәтебез, тормышта терәгебез. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Хурлык, хурлык, хурлык – әниләре картаеп та, аларга кадер-хөрмәт күрсәтеп, үзләренә җәннәттә урын әзерләмәүчеләргә», – ди.

Әлкама исемле бик диндар кеше яшәгән. Бервакыт ул телсез калган, хәтта шәһадәт кәлимәсен дә әйтә алмаслык хәлгә килгән. Пәйгамбәребез (с.г.в.) бу егетнең әнисен чакыртып, аннан улы турында сөйләвен сорый. Әнисе исә:

– Йә Рәсүлаллаһ, Әлкама бик яхшы кеше, гыйбадәтен калдырмый, тик минем аңа бер шелтәм бар. Ул миңа караганда, хатынының ризалыгын алырга, күңелен күрергә тырыша. Аны якынрак күрә, аңа яхшырак мөнәсәбәттә, шуңа күңелем рәнҗи, – ди.

– Шуның өчен дә ул телсез калган, гафу ит син аны, – ди Пәйгамбәребез (с.г.в.).

– Йә Рәсүлаллаһ, – ди ана. – Ул мине рәнҗетте. Гафу итә алмыйм.

– Йә, Билал, – ди Пәйгамбәребез (с.г.в.). – Учак як. Бу ана баласыннан риза түгел. Ананы рәнҗеткән Әлкаманы утка атыгыз!

– Йә Рәсүлаллаһ, – ди ана, – мондый җәза бирә күрмәгез. Ана йөрәге моңа түзмәячәк.

– Әй ана, – ди Пәйгамбәребез (с.г.в.). – Тәмуг уты – учак утыннан зәһәррәк, күпкә көчлерәк. Әгәр дә ул сине рәнҗеткән икән, тәүбәгә килеп төзәлмәгән һәм син аны гафу итмәгәнсең икән, аңа гыйбадәте дә, намазы да шәфкатьле булмас, ул җәһәннәмгә эләгер. Аны шунда күреп ничек түзәрсең?

Ана улын гафу итә. Улы тәүбәгә килә, шәһадәтен теленнән төшерми. Анадан олы кеше юк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Хатын-кызны яратыгыз, чөнки ул – сезнең әниегез, сезнең балаларыгызның әнисе, сезнең кызыгыз, апагыз, сеңлегез, кыз туганыгыз», – ди. Анага, хатын-кызга ислам динендә аеруча хөрмәт күрсәтергә боерылган, чөнки һәрбер бөек ир артында бөек хатын-кыз тора. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Җәннәт – аналарның аяк астында», – ди. «Әниеңне, әниеңне, әниеңне, аннан соң әтиеңне хөрмәт ит» дигән хәдис тә бар.

## Чаллы яңалыклары





Мәүлид бәйрәме уңаеннан Чаллы мәчетләрендә матур чаралар уздырылды. "Туфан" мәчетендә Равил хәзрәт Нуруллин бу бәйрәмнең асылы турында вәгазь сөйләде; чарага килгән ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен табын да әзерләнгән иде, зәм-зәм суыннан авыз итәргә дә мөмкинлек тудырылды. "Әбүзәр" мәчетендә дә шундый әчтәлектәге игелекле чара үтте, имам-хатыйб Али хәзрәт Багаутдинов бәйрәмгә килгән мәхәллә картларына бүләк-күчтәнәчләр таратты. ГЭС мәхәлләсе мәчетендә Габдерәшит хәзрәт Курмалеев Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) сыйфатлары турында вәгазь сөйләде, соңыннан җәмәгать белән дүрт рәкәгать тәсбих намазы укылды. "Утыз Имәни" мәчетендә узган бәйрәмдә Салихҗан хәзрәт Гайниев мәчеткә килгәннәрне Мәүлид белән котлап, Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) күркәм холкы турында вәгазь сөйләде; биредә дә, калган мәчетләрдә дә вәгазьләр тыңланылды, пәйгамбәребез рухына багышлап, догалар кылынды, Коръән аятьләре укылды, салаватлар әйтелде.



## ТР МДН хәбәр итә





Болгар ислам академиясе бинасында Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) туган көненә багышланган Мәүлид кичәсе узды. Бәйрәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Болгарда алтынчы тапкыр оештырылды. Тантанада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының «Милли Шура» рәисе В.Шәйхразиев, Болгар ислам академиясе Президенты К. Исхаков, Спас муниципаль районы башлыгы К. Нугаев, шулай ук дин һәм дәүләт эшлеклеләре, Россия төбәкләре мөфтиләре, мөхтәсибләр һәм Татарстан мәдрәсәләре вәкилләре катнашты.

***



Казанның Кабан күле яр буенда бөек татар галиме, дин әһеле, фәлсәфәче Шиһабетдин Мәрҗанигә һәйкәл ачылды. Чарада ТР Президенты Р. Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе М. Шәймиев, Татарстан мөфтие К.Сәмигуллин һ.б. катнашты. Тантанага шулай ук Мәрҗанинең нәсел дәвамчылары, танылган галимнәр, дин, әдәбият һәм сәнгать әһелләре, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләре, җитәкчеләр килгән иде.

Быел Мәрҗанинең тууына 200 ел тулды. Шул уңайдан 2018 ел Республикада Мәрҗани елы дип игълан итедле һәм аның кысаларында Диния Нәзарәте тарафыннан төрле юнәлештәге чаралар үткәрелде, галимнең хезмәтләре дөнья күрде.

## "Ихсан" фондында – яңа акция

"Ихлас" мәчетендә "Ихсан" хәйрия фонды тарафыннан ялгыз әниләр, тол аналар һәм аларның балалары өчен "Мама может" дигән игелекле акция уздырылды. Ислам дине кешеләргә шатлык бүләк итүне, авыр хәлдә калганнарга ярдәм кулы сузуны, мөмкин булганча булышуны хуплый, әлеге чара да шундый максаттан оештырылды. Хатын-кызлар, берничә сәгатькә булса да тормыш мәшәкатьләреннән арынып торып, үзара җылы мохиттә аралаштылар, тәлинкәләр бизәү буенча мастер-класста катнаша алдылар; гаилә психологы белән күзгә-күз карап сөйләшү дә үз сорауларына җавап табарга беркадәр ярдәм итте. Ә балалар исә "Хәзинә" клубының тәҗрибәле мөгаллимәләреннән мастер-класс алып, тәмле пицца пешерү серләренә төшенделәр, рәхәтләнеп уйнадылар. Соңыннан бергәләп чәй эчкәндә, мондый кичәләрнең күпләр өчен рухи терәк булуын тагын бер кат ассызыклап, аларны ай саен үткәрү кирәклеге хакында да фикер алыштылар.

# Байлыкка омтылуның зарары

*Габдулла бин Гамр радый Аллаһу ганһүмәдән риваять кылына, Расүлуллаһ (с.г.в.) әйтте: «Бу өммәтнең төзәлүе якыйннан (ягъни Аллаһы Тәгаләгә булган ныклы ышанычтан, иманудан) һәм бу дөньядан аерылудан башланды. Һәм аның түбәнчелеккә төшүе дә комсызлыктан һәм килачәккә булган зур өметләрдән башлана". (Шүгбәл-иман, 10429)*

Мин байлыкка омтылмаска, киресенчә, байлыктан сакланырга кирәклеге турында вәгазь сөйләгәч, ризасызлык белдерүчеләр, байлыкка омтылырга кирәк, дип әйтүчеләрне ишетергә туры килде. Шуңа күрә бу темага кабаттан кайтырга булдым. Чөнки динебезнең ныклыгы өчен бу иң әһәмиятле нәрсәләрнең берсе. Беренче карашка кешенең баюы диннең ныгуына гына китерә кебек. Кеше баеган саен сәдакасын күбрәк бирер, ятимнәргә, мәчет-мәдрәсәләргә ярдәм итәр, мөселман өммәте баер, дин күтәрелер кебек тоела. Әмма, ни гаҗәп, тормышта киресенчә була. Байлыкка бәйләнгән һәрнәрсә ахыр чиктә юкка чыга, бетә. Ислам өммәтенең күтәрелүе дә байлыктан ваз кичү белән башлана. Пәйгамбәребез (с.г.в.) Мәккәнең иң бай хатыны булган Хәдичә радый Аллаһу ганһәгә өйләнә. Шул байлыкны дин юлына сарыф итә һәм, үзе белән бер әйбер алмыйча, Мәдинәгә хиҗрәт кыла. Әбү Бәкер, Гомәр радый Аллаһу ганһеләр һәм башка күп кенә сәхәбәләр үзләренең бөтен байлыкларын Аллаһ юлына тоталар. Һәм күп тә көттерми, Аллаһы Тәгалә аларга җиңү артыннан җиңү биреп, аларның дөнья малларына хуҗа булуларын насыйп итә. Бу алда әйтелгән хәдискә дәлил булып тора, Ислам диненең, ислам өммәтенең ничек күтәрелүен күрсәтә. Һәм хәдиснең икенче яртысы безне өммәтнең түбәнчелеккә төшәргә дә мөмкин булуы белән кисәтә. Дөнья бит ул фәкать сынау йорты гына. Ә ахирәт йорты мәңгелек.

28.83. «Бу ахирәт йортын Без иман китерүдән һәм Аллаһыга буйсынудан-итагать итүдән олугъланмаган һәм җир өстендә бозыклык кылмаган хак мөэминнәр файдасына кылырбыз, җәннәт Аллаһы риза булмаган эшләрдән сакланучыларга, ягъни тәкъва мөэминнәргәдер».

Дөнья ничек алып барсаң дә көннәрдән беркөнне бетә. Дөньядагы авыр тормышны җәза итеп, яхшы бай тормышны бүләк итеп кабул итәргә кирәк түгел. Алар икесе дә фәкать сынау һәм вакытлыча гына. Аллаһы сөбханәһү вә тәгалә әйтә: 21.35. "Без сезне яманлык һәм яхшылык белән фетнәләп сыныйбыз, соңыннан хөкемгә безгә кайтырсыз».

Дөнья байлыгын Аллаһы Тәгалә мөэминнәргә дә, кәферләргә дә бирергә мөмкин. Хәтта кәферләргә күбрәк тә бирергә мөмкин. Чөнки пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткәнчә, дөнья байлыгы Аллаһы Тәгалә өчен черкинең сыңар канатына да тормый. Ә туры юлга Аллаһы Тәгалә үзенең сөекле колларын гына кертә һәм Ул анда аларны Үзенең рәхмәте белән генә кертә, без яхшы булган өчен түгел, бәлки үзенең теләге белән. Байлыкка килгәндә исә, киресенчә, Аллаһы Тәгалә Үзенең яраткан колын байлыктан саклый, аны байлыктан ерак кыла. Расүлуллаһ (с.г.в.) әйтте: «Әгәр Аллаһы Тәгалә Үзенең бер колын яратса, авыруны судан саклаган кебек, Ул аны дөнья малыннан саклый». (Тирмизи, 2036). Ягъни без кызыга торган һәм без ирешә алмый торган байлык, чынлыкта, ул Аллаһының саклавы нәтиҗәсе. Күңелендә иманы булмаган кешенең дөньяга омтылуы телевизор каршында утырган кеше мисалы кебек: телевизор сүнгән кебек, үлем белән бу дөнья сүнә, андагы бер нәрсә дә калмый, экран ябыла, хаклык кала, әмма хаклыкка бер нәрсә дә хәзерләнмәгән була. Кеше күпме генә дөнья малы артыннан чапса да, дөнья малының аңа барыбер тәкъдиренә язылганнан артыгы ирешмәячәк. Дөнья малын гына өмет иткән кеше бу дөньяда да бәхеткә ирешә алмый һәм ул ахирәттә дә бәхетсез булачак. Ә инде дөнья малына алданмаган, дөнья малын өмет итмәгән, киресенчә, ахирәтне өмет иткән, күңеле иман белән тулган кеше бу дөньяда да бәхетле: чөнки ул бар булганына канәгать, Раббысына шөкер итә, Аллаһы насыйп итсә, ул ахирәттә дә бәхетле булачак. Ә дөнья малына килгәндә исә, тәкъдиренә язылганы барыбер аңа ирешәчәк. Кеше кулында малы, дәрәҗәсе бар вакытта үзенең үлеме турында, кыямәт көне турында, Аллаһу сөбханәһү вә тәгалә турында уйламый. Ә бит үлем безнең уйлау-уйламаудан тормый, гомер адәм баласына тәкъдиргә язылган кадәр бирелгән. Шулай ук мал да, дәрәҗә дә күләме белән дә, күпме вакытка бирелүе белән дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән. Кергән малга алданырга кирәк түгел, вакытында зәкәтен чыгарырга кирәк. Булган малларда мохтаҗларның да өлеше барлыгын онытмаска кирәк. Бирелгән малның, дәрәҗәнең кулда булырга тиешле вакыты узар, Аллаһы Тәгалә төрле юллар белән ул малларны, дәрәҗәләрне алыр. Маллар да, дәрәҗәләр дә бетәр, ахирәткә дә бернинди әҗер-савап ирешмәс. Кичә генә малга-дәрәҗәләргә ия булган кеше бүген үзе үк мохтаҗлыкта калырга мөмкин.

Иң алда телгә алган аятькә әйләнеп кайтыйк. Байлыкны бернәрсәгә санамаган өммәт тиз арада бөтен дөньяның байлыгына ирешә, ягъни дөнья байлыклары мөселманнарның аяк астында кала дип әйтсәк, дөреслеккә турырак килә торгандыр. Бу чорда да, әлбәттә, төрле кешеләр булгандыр, әмма мөселман өммәтен әйдәп баручылар үзләренең пәйгамбәрләре үрнәгендә байлыкка битараф булып кала алганнар. Монда берничә мисал карап китсәк урынлы булыр. Риваять кылына, Гомәр радый Аллаһу ганһе пәйгамбәр (с.г.в.) янына керде. Пәйгамбәр (с.г.в.) камыш намазлык өстендә иде, янында хөрмә яфракларыннан тукыма палас бар иде. Гомәр радый Аллаһу ганһе елады. Пәйгамбәр (с.г.в.) әйтте: «Әй, Гомәр, сине нәрсә елата?» Гомәр радый Аллаһу ганһе әйтте: «Син Фарси патшасы Кәсраны һәм Рум императорын зикер иттең, аларның дөньяда нинди хәлдә булуын әйттең һәм синең яныңда хөрмә паласыннан башка нәрсә юк, ягъни алар алтын-көмеш тәхетләрдә, йомшак ятакларда, ә син камыш паласта», диде. Шунда пәйгамбәр салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Алар өчен - бу дөньяда, безнең өчен - ахирәттә».

Бу чорга караган мисалларны күп китереп булыр иде. Әмма бу чор мөселманнарына алмашка башкалар килә, аларның диннәре күбрәк телдә була, байлыкка мәхәббәт арта, башкаларны дингә тарту урынына алар диннән гаделсезлек эзләп, диндә гаделлек урнаштыруга алынып зур фетнәләр чыгаралар, ахырда исән вакытларында җәннәт белән шатландырылган олуг сәхәбәләрдән булган Госман һәм Гали радый Аллаһу ганһеләрне үтерүгә кадәр барып җитәләр.

Байлык бер кешегә дә, милләткә дә шатлык китерми. Советлар Союзы таркалганда бар халык та чагыштырмача бер чама иде, бай түгел иде. 1992 елда «Тәүбә» мәчете ачылганда, халык бер яклап «Студенческая» тукталышыннан, икенче яклап «Пединститут» тукталышыннан «Тәүбә» мәчетенә кадәр араны биләп тора иде. Бүгенге көндә кешенең ай кую түгел, гает намазына килергә дә вакыты юк, чөнки аның байлыгы бар, байлык җыярга мөмкинлеге бар.

90нчы еллар башында илдә үзгәртеп корулар башланганда милләтне күтәрергә тиешле, суверенитетка алып барырга тиешле кайбер лидерларыбыз: «Без бай милләт булырга тиешбез, безнең дә үз байларыбыз булырга тиеш», дигән лозунглар күтәреп чыктылар, алар теләкләренә ирештеләр, үзләре баедылар. Тик нигәдер мәчетләргә генә йөрмиләр. Бүгенге көндә дөньякүләм иң бай кешеләр арасына керүчеләр арасында татар байлары да бар. Әмма аларның байлыгыннан дингә дә, милләткә дә бер файда да юк. Бүгенге көндәге күп мәчетләр халык байлыкка күнекмәгән, изләшмәгән вакытта салындылар. Ә бүген исә салынган мәчеттә мулла тотарга шул халыкның акчасы җитми. Халык байый, ә милләт исә тагын да ныграк упкынга тәгәри. Байларыбызга инде милләт кирәкми, алар үзләренең телләрен дә, диннәрен дә белмиләр, инде үзләрен дә башка милләт кешесе дип саныйлар, балаларын да чит илләрдә укыталар, чит ил гражданнары булып торалар, хәтта диннәрен алыштыручылар да аз түгел. Димәк, байлык милләт өчен бернинди уңай нәтиҗәләргә китермәде. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: Кагеб ибне Мәлик әл-Ансаридән риваять ителә, Расүлуллаһ салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Сарыклар көтүенә җибәрелгән ике ач бүре, байлыкка һәм абруйга, ягъни дәрәҗәгә омтылган кешедән дингә килгән зыяннан артык зыян сала алмаслар». (Тирмизи, 2550)

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм байлыкка һәм абруйга омтылудан дингә килгән зыянны сарык көтүендә калдырылган ике ач бүренең зыяныннан артыграк, дип, байлыкка һәм абруйга омтылуның никадәр зыянлы булуларын күрсәтә.

Дөрес аңлагыз, мин байларны сүкмим. Байлык Аллаһы Тәгаләнеке һәм ул аны Үзе теләгән колына гына бирә. Минем вәгазем байлыкка, дәрәҗәгә омтылуның зыяны турында. Мәчетләргә болай да байлар йөрми иде. Хәзер бай булмаганнары да йөрми. Тормыш авырлыгына дәүләтне сүгәргә кирәк түгел. Бүген эчкечелеккә, бозыклыкка бирелмәгән бөтен кеше дә тормышын уртача булса да алып бара ала. Әмма уртача тормыш бүгенге кешенең нәфесен канәгатьләндерми, аның байлар кебек яшисе килә, ягъни аның да яхшы фатирларда торасы, яисә үз йортын булдырасы, кыйммәтле машиналарда йөрисе килә. Максатына ирешү өчен ипотека ала, кредитка керә, бурычлы була. Ул үзе дә сизмәстән үзенең нәфесенең колына әверелә. Аның мәчеткә йөрергә вакыты, сәдака бирергә акчасы калмый. Ә бит ул тормышын ипотекасыз, кредитсез, бурычсыз да алып барыр иде.

Госман ибне Гаффән радый Аллаһу ганһедән риваять кылынган, пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Адәм баласының яшәү өчен йорттан, гаурәтен каплау өчен киемнән, шулай ук бер кисәк икмәктән һәм судан башка бернәрсәгә дә хакы юк (ягъни кыямәт көнендә кеше бу нәрсәләр өчен соралмас)». (Тирмизи, 2512)

Бүген вәгазь байлыкка омтылуның зыяны турында булды. Бу мөмкинлегең бар булып хәерчелеккә омтылу дигәнне аңлатмый, бәлки тормышның мәгънәсе байлыкка омтылу булырга тиеш түгеллеген генә аңлата. Байлыкка омтылып кына байлыкка хуҗа булып булмый. Кем нәрсәне күбрәк ярата - ул шуның колы була. Раббысын яраткан кеше Раббысының колы була, дөньяны яраткан кеше дөньяның колы була.

Кеше фәкать икенең берсенә омтыла: яисә дөнья нигъмәтләренә, яисә Аллаһ ризалыгына. Ничек кенә булса да бу дөнья беркөн һәрбер кеше өчен бетәчәк. Кыямәт көне турында онытмасак иде. Байлар байлыклары хакында соралсалар, фәкыйрьләр сабырлыклары хакында соралырлар.

Габдулла бине Гамрдән, радый Аллаһу ганһүмә, риваять кылына, Расүлуллаһ салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Кыямәт көнендә сез җыелырсыз. Һәм әйтелер: «Кайда бу өммәтнең фәкыйрьләре һәм мескеннәре?» Алар торып басарлар. Һәм алардан «нинди гамәлләр кылдыгыз?» дип сорарлар. Алар: «Ий, Раббыбыз, син безне сынадың һәм без сабыр иттек, син байлыкны һәм солтанлыкны башкаларга бирдең», дип җавап бирерләр һәм алар җәннәткә башкалардан иртәрәк керерләр. Хисабның катылыгы байлыгы һәм хәкимлеге бар кешеләрдә калыр».

Адәм баласы дөньяга артык бирелмәсен өчен Аллаһы Тәгалә кисәтә: 63.9. Ий, мөэминнәр, сезне малларыгыз һәм балаларыгыз Аллаһы зикереннән алдамасын, намаздан туктатмасын һәм Коръән белән гамәл кылудан гафил итмәсен. Әгәр бу эшне берәү кылса, ягъни малына һәм балаларына алданып иманына, диненә кимчелек китерсә, андый кешеләр ахирәттә газапта булып хәсрәтләнүчеләрдер.

Аллаһы Тәгалә һәммәләребезне дә ахирәт өчен тырышучы тәкъва колларыннан насыйп кылсын.

**Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев, Чаллының "Ак мәчет" имам-хатыйбы.**

## БЕЛӘСЕЗМЕ?

Духа намазының вакыты кояш чыкканнан соң намаз укыр өчен мәкруһ вакыт узгач башлана һәм кояш зәвәлгә якынлашуга тәмамлана (өйлә намазының вакыты керергә 20-40 минут кала). Духа намазы иң азы 2 рәкәгатьтән, иң күбе 12 рәкәгатьтән тора. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: "Кем даими рәвештә 2 рәкәгать духа намазы укыса, аның (кече) гөнаһлары кичерелер, хәтта алар диңгездәге күбек кебек күп булса да". "Кем 12 рәкәгать духа намазы укыса, шуңа Аллаһ җәннәттә сарай төзетер". "Һәр иртә һәрбер буыныгыз өчен сәдака бирергә кирәк. Һәрбер тәсбих (сөбханаллаһ сүзе) – сәдака, һәрбер тәхмид (әлхәмдулиллаһ сүзе) – сәдака, һәрбер тәхлил (ләилаһә иллаллаһ сүзләре) –сәдака, һәрбер тәкбир (Аллаһу әкбәр сүзләре) – сәдака. Һәм яхшылыкка өндәү – сәдака, һәм начарлык эшләүдән тыю – сәдака. Әммә боларның һәммәсен духа намазының ике рәкәгате алыштыра".

*("Ислам дине нигезләре"ннән)*

*Ришат Курамшин*

# Соңгы сынау

*(Хикәя)*

Кояш урман артыннан күтәрелеп, сүрән нурлары белән авыл ихаталарын сизелер-сизелмәс яктырта башлауга ук, өчимәнлеләр Нургали абый белән Кәүсәрия апа турындагы шомлы хәбәрне кабалана-кабалана бер-берсенә тапшыра башлады. Авылның хөрмәтле абыстае һәм мөхтәрәм аксакалы булган әби-бабайны кичә төнлә бер исерек машинасы белән бәрдерәп киткән... Урамда кап-караңгы иде, шулай да, машина номерын күреп калучылар булгач, гаепле кешене бик тиз эләктергәннәр үзе, ләкин... халык бик яраткан, олы ихтирамга ия булган ике өлкән кешенең хәле бик авыр икән, бик авыр... Күр син аны: Рамазан аенда, төнге тәравих намазыннан кайтканда шундый бәлага тарыганнар бит, ә!

Нургали абый белән Кәүсәрия апаны район хастаханәсенә бергә, ике кешелек аерым палатага яткырдылар. Илле елга якын бер гаилә булып гомер кичергән әби белән бабайны аермыйча, бер-берсенә иптәш вә терәк булырлар дип, шулай бергә урнаштырганнар иде. Улы Саха республикасының Мирный шәһәрендә, кызы исә бөтенләй чит илдә – Германиядә яшәгәнлектән, аларны башта борчымаска булдылар, әмма соңрак, бабайның хәле начарайгач, хәбәр итеп чакырттылар. Хәер, якын туганнары янда булмаса да, палатадан халык бер дә өзелеп тормады: күрше-күлән, мәчет картлары, башка авылдашлары килеп, күчтәнәч тә китерде, кечләреннән килгәнчә ярдәм дә итте. Сигезенче дистәне ваклап баручы карт белән карчыкка авыл халкының зур хөрмәт күрсәтүе алар ихласлы дин әһелләре булган өчен генә түгел, күркәм холыкларына, ачык, нурлы йөзләренә дә бәйле иде. Моннан тыш әле яшь чакларындагы танышу хатирәсе дә үзенә күрә бер сәбәп булды. Шушы тормыш хәле, менә инде берничә дистә ел дәвамында авыл тарихына мөнәсәбәтле кызыклы кыйсса буларак, буыннан буынга, телдән телгә күчеп килде. Аны ишеткәч, кемдер елмайды, кемдер хискә бирелеп, күз яшьләрен тыя алмыйча елады, әмма күпләр бу хәлне олы бер гыйбрәт вә хикмәтле сабак итеп кабул итте...

...Яшь чагында Нургали агач ташый торган зур йөк машинасында эшләде. Ул вакытта, техника аз булу сәбәпле, машина йөртүчеләрне бик еш нормадан арттырып эшләттеләр, кайвакытта хәтта төнен дә юлга чыгарга туры килде. Менә шундый караңгы төннәрнең берсендә тәмам алҗыган егет рульдә барганда йоклап китә һәм аның юан бүрәнәләр төялгән машинасы тирән ерымга әйләнеп төшә. Ярый әле арттан МТС тракторы кайткан була. Тракторчы абзый, ауган йөк машинасын күреп, авылга чаба һәм ашыгыч ярдәм белән милиция хезмәткәрләрен чакыра. Фаҗига урынына килеп җиткән табиб исә... суламыйча яткан егетнең авыр җәрәхәтләрдән һәлак булуын белдерә. Каты яраланып, канга буялып беткән гәүдәдә, чыннан да, җан әсәре барлыгы сизелми иде. Инде нишләргә – медицина хезмәткәре шоферның үлемен рәсми рәвештә раслагач, "мәетне" район үзәгендәге моргка илтеп куялар. Шунда берничә сәгать ятканнан соң, егет, Аллаһның безгә мәгълүм булмаган тәкъдире белән, аңына килә. Бик каты туңганын һәм яраларның хәйран авырттырып сызлавын тойган егет беравык үзенең кайда икәнен аңыша алмыйча ятты. Ләкин яралары бәйләнмәгәнен, тимер ятагында ни матрасы, ни юрганы булмавын сизгәч, кайда әләкәнен чамалый башлады: "Йә Хода... Мине үлгән дип белеп, мәетләр саклагычына китереп куйганнар түгелме соң... Моргта бит мин...". Әлеге шомлы, тетрәндергеч уй Нургалиның күңелен тәмам пошаманга салды. "Шушы зәһәр салкын, караңгы, куркыныч урында тагын күпме ятарга туры килер икән?.. Озакка китсә, чыннан да үлеп, җаның белән хушлашырга туры килмәгәе...".

Күңел төпкелендә пыскып торган яшәү өметен чарасызлык күләгәсе кара шәүләсе белән каплый башлаган мәлдә, дөм караңгы бүлмәнең шомлылыгын тагын да арттырып, кемнеңдер сулкылдап елаган тавышы ишетелде. "Саташам бугай...", – дип уздалдына уйлап куйды егет. Ләкин яндагы елау тавышы тукталмагач, кымшанудан җәрәхәтләрнең каты авыртып алганын сизеп алса да, гаҗәпләнү хисе тәэсирендә, Нургали бераз күтәрелеп, башын тавыш ишетелгән якка борды.

- Әй... Кем бу?.. – дип караңгыга аваз салган егет үзенең хырылдап чыккан тавышыннан сискәнеп куйды. – Монда кемдер бармы?..

- Бар... – диде бер хатын-кыз, һәм борынын мышкылдатып: "Мин бу...", – дип өстәде дә үкси-үкси елавын дәвам итте.

- Кем "мин"? – Әле генә чыгып китә язган котының әкрен генә урынына урнаша башлавын тойган Нургали шушы кешеләрчә бирелгән җаваптан бераз тынычлана төште. – Исемең ничек соң синең?

- Кәү...сәрия... – диде тавыш иясе, исеменең беренче һәм икенче иҗекләре арасында янә мышык-мышык килеп.

- Ә мин Нургали... – Янында исән кеше булуына анык төшенгәннән соң, егет сөенеченнән торырга талпынды, әмма башындагы яраның үзен кинәт "белдереп" алуыннан ыңгырашып куйды да, янә урынына ауды. Соңыннан исә, бераз тынычлангач, кечәнмәскә тырышып, әкрен генә тагын бер соравын бирде:

- Ә син, Кәүсәрия... безнең кайда ятканыбызны беләсеңме?

- Морыгта... – дип җаваплады "елак тавыш", шушы сүзнең мәгънәсенә әллә ни исе китмәгәндәй.

- Менә мин дә аны шулай уйлаганием... – диде Нургали, һәм беравык дәшмичә ятканнан соң, сөйләшүне дәвам итте:

- Кәүсәрия... Син монда ничек эләктең соң?

- Баттым... – дип кыска һәм беркатлы җавап бирде тавыш караңгы почмактан. – Ә син?

- Ә мин... рульдә чакта йоклап китеп... машинам белән чокырга әйләнеп төштем...

Бүлмәдә тынлык урнашты. Бер-берсенең җавабыннан хәйран калып, егет белән кыз күпмедер вакыт гаҗәпләнеп дәшмичә ятты. Чыннан да, ышанырлык хәл мени? Бер көнне "үлеп", бервакытта "терелгән" ике "мәет" бер урында шулай очрашсын әле? Шаккатырлык тәкдир галәмәте булмый, тагын ни булсын? Йә Аллаһ...

Шул вакытта үзләрен кабер эчендә яткандай тойган яшьләрнең күңелләре бербөтен булып, олы, якты дөньяга чыгу максатына ирешүдә бер-берсенә сүзсез генә ярдәм итешергә вәгъдә бирде. Җәрәхәтләре каты сызлаудан, төнге салкын үзәкләргә үтеп тундырудан гаять җәфаланып ятса да, Нургали җаны тернәкләнеп китүен һәм яшәү дәрманына ия булуын сизде. Кәүсәрия дә, читтәрәк яткан егетнең ни кыяфәтен күз алдына китерә алмаган, ни холык-фигыльләрен белмәгән килеш, аның шушы минутларда үзе өчен дөньядагы иң якын, иң кирәкле кеше булуын аңлады.

- Нургали...

- Әйе, Кәүсәрия...

- Бик суык монда... Туңдым мин, Нургали... Ни кулларымны, ни аякларымны тоймыйм...

Үзенең нинди хәлдә булуын абайлап бетермәгән егет, яраларның авыртуына көч-хәл белән түзеп, башта күтәрелеп утыра, аннары идәнгә төшеп, иреннәрен тешли-тешли, үрмәләп-шуышып дигәндәй, тавыш ишетелгән якка хәрәкәтләнә башлый, ләкин кыз яткан сәндерәгә кадәр килеп җиткәч, хәле бетеп ыңгырашып ала да, туктап кала. Каты туңдан һәм күрше "мәетнең" янына үк килеп туктавыннан тәмам куркуга төшкән кыз тагын да ныграк калтырана башлый. Әмма кытыршы кулның беләгенә кагылуын тойгач, әүвәл сискәнеп алса да, бераздан тынычланып киткәндәй була.

- Кәүсәрия... Монда төшә аласыңмы? Төшсәң, бер-беребезгә сыенып җылынып идек, дим...

Бер-берсенә инде сыенырга өлгергән ике җанның калып-гәүдәләре дә берләшкәч, калебләр төбендә пыскып торган өмет чаткысы зураеп, ныграк, ышанычлырак итеп яныш китте, хәтта... олы мәхәббәт ялкынына әверелеп, бу бүлмәне генә түгел, бар дөньяны – хәзерге һәм алдагы тормышны сөенечле яктыртып җибәрде.

Соңыннан иртәнге якта килгән санитарның бер-берсенә елышып утырган ике "мәетне" күргәч ничек кычкырып җибәрүен дә, яралардан йөзе ертылып, шешенеп, зәңгәрләнеп бетү сәбәпле әкиятләрдәге куркыныч диюгә охшаган егеткә берсүзсез кияүгә чыгарга ризалашкан Кәүсәриянең кешелекле гамәлен дә авыл халкы җәй чыккан саен кызык бер хәл итеп искә алды. Чыннан да, Нургалиләр өенә килен булып төшкәндә, Кәүсәрия аның бу төбәктәге иң чибәр, иң уңган-булган егетләрнең берсе икәнен белмәде. Умыртка баганасы бераз зарарланган булгач, Нургалигә ярты ел чамасы урын өстендә ятарга туры килде. Шул вакытта нәкъ менә Кәүсәрия аңа үз-үзенә ышанырга ярдәм итте, кайчакларда ире төшенкелеккә бирелеп, күңеле сүрелсә, шаяртыбрак: "Теге төнне морыгта минем янга килә алдың бит? Димәк, аякка басасың, Аллаһ боерса!" – дип юата иде үзен. Ә терелгәч, Нургали шөкер йөзеннән аякка гына түгел, намазга да басты. Хәләл җефете дә дин юлын үз итеп, намаз иясе дә булды, авыл абыстае ярдәме белән гарәп хәрефләрен үзләштереп, Коръән укырга да өйрәнде. Өлкән яшьтәге абыстай вафат булгач исә, аның вазифаларын Кәүсәрия башкара башлады.

*(Дәвамы бар).*

ӘДӘБИ СҮЗ

## Мәчетләргә юл ачык

Бу гүзәл, якты дөньяны
Раббыбыз хасил иткән.
Ризык итеп, тел йотарлык
Нигъмәтләр жиргә сипкән.
Гыйлемле булсын инсан дип,
Изге Коръәнен биргән.
Китабын укып белгәннең
Күңелен акка күмгән.
Изге китап сүзләреннән
Чыкмаган әби-бабам.
Зикер әйтеп, тәсбих тартып
Раббысын олылаган.
Көмеш айлы манаралар
Ямь өстәгән авылга.
Азан моңын ишетүгә
Халкым баскан намазга.
Булган вакыт...
Яралаган күп җаннарны
Имансызлык дәвере.
Җимерелгән мәчетләрне
Саклый халкым хәтере.
Динебездән яза яздык,
Яшердек Коръәннәрне...
Күпме гөнаһ, хата, ялгыш,
Уйласак үткәннәрне...
Иншәаллаһ, инде хәзер
Мәчетләргә юл ачык.
Калебләрне чистартырга
Йә, халкым, әйдә, ашык!
Коръән нурына коенып,
Укыйк без аять-сүрә.
Гыйбадәт кылган колларын
Рабыббыз якын күрә.
Динебез хак, камил, күркәм,
Нигезе аның – иман.
Бу бүләкләрне җибәргән
Раббыбызга мактау, дан!

## Дога кылып яши аналар

Һәрбер ана балам-бәгърем диеп,
Ожмах ясап назлы куенын,
Ачык зиһен, саулык, гомер теләп,
Үстерәдер газиз сабыен.
Бар күңелен салып тәрбияли,
Бассыннар дип тизрәк аякка.
Тик балалар канат ныгыткач та
Таралалар очып еракка.
Кыз-уллары читтә, ә ул көтә,
Бар сыеннан табын тутырып.
Ана өчен бәйрәм – бала белән
Чәй эчүләр бергә утырып.
Йөрәк парәсенә бәхет сорап
Дога кылып яши аналар.
Кыен чакта газиз баласына
Җанын бирергә дә ризалар.
Әй балалар, кайда торсагыз да –
Каламы ул, әллә саламы,
Ожмах – ана аяк астында бит,
Калдырмагыз ялгыз ананы!

**Фәнисә Фәхретдинова,**
**Башкортстанның Кушнаренко районы Әхмәт авылы.**

# Чын әни нинди була?

Чын әни нинди булырга тиеш – башта шуннан башлыйк әле. Бүген безнең хатын-кызларыбыз өчен беренче чиратта уку мөһим, аннары акчалы эш, аннары карьера. Аннары вакыт калса, бәлки, берәр бәби табармын әле, ди ул. Кайсы кияүгә чыга алмый кала шунда, кайсының вакыт үтеп киткән була...

Бүгенге җәмгыятьтә шулай ук дөрес булмаган тагын бер күренеш бар. Берәр очрашуга чакыралар да, менә бу галимә хатын-кыз, менә шагыйрә хатын-кыз, менә җырчы хатын-кыз, менә депутат хатын-кыз, дип аны түргә утыртып куялар... Госсоветта йоклап утыру өчен хатын-кыз булу мәҗбүри түгел бит ул, аны ирләр дә эшли ала. Мин бу эшләрне хатын-кыз эшләмәсен дип әйтмим, әмма аның беренче вазыйфасы – бәби табып тәрбияләү, ул башта үз эшен эшләсен. Бүген, милләтне ничек саклап калырга, дип әллә нинди чаралар, форумнар уздыралар. Моның өчен ике генә әйбер кирәк: бөтен татар хатыны татарча сөйләшә торган ким дигәндә 3 бала үстерергә тиеш; шул балалар ун яшьтән намазны ятлаештерергә кирәк ихластан укый торган булырга тиеш. Милли-дини-демографик проблема шуның белән чишелеп бетә! Бүген һәр биш хатын-кызның берсе бәби таба алмый. Ике генә бала табып без милләтне алга таба алып бара алмыйбыз. Өч бала алып кайтмаган икән, ничу аны президиумга утыртып, профессиясе өчен мактарга!

**Җәлил хәзрәт Фазлыев,**
**Татарстанның баш казые.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

* Күкләр һәм Җир – Аллаһның милке. Үз теләгәнен бар итәр. Теләсә – кыз балалар бирә, теләсә – ир углан бүләк итә

* Үз балаларыгызны хөрмәт итегез һәм яхшы тәрбия кылыгыз

* Ата-анасы канәгать булган кешеләр алдында Җәннәт капкалары, канәгать булмаганнары алдында – Җәһәннәм капкалары ачылыр

* Кеше фани дөньядан киткәч, аның гамәлләреннән бары тик өчесе генә кала: хәйрия җимешләре, белеме, аның өчен дога кылучы баласы

* Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр

* Аллаһның ризалыгы – әти-әниеңнең ризалыгында, Аллаһның ачуы – әти-әниеңнең ачуында

*Безгә язалар*

# Хәләл ризык – җан саулыгы



Әссәламугаләйкум, үзем яратып, көтеп алып укый торган "Ислам нуры" газетасы! Вәгазьләрнең хәрефен дә төшереп калдырмыйча укып чыгам, шигырь-хикәя җибәрүчеләргә дә Алланың рәхмәтләре булсын, барысы да кеше өчен бик файдалы. Менә үзем дә сезгә хат язарга булдым әле. Хәзер хәләл кафе-рестораннар бик күп, Аллага шөкер. Элегрәк кенә аның ишене белмәдек бит. Беркөн ирем белән Сидоровкадагы Закамье базасына барган идек, яшелчәсе, җиләк-җимеше кирәк дигәндәй... Төшке аш вакыты җиткәндә, ирем өйгә кайтуны сөйли башлады. Килгән-килгән, шушында гына әбәдлик тә, җыясы әйберләрне иркенләп җыйыйк инде, дим үзенә. Кешедән белешеп, администрация бинасындагы хәләл кафега кердек. Минем картым алай өйдән читтә ашап йөрүне өнәп бетерми иде, теләр-теләмәс кенә керде. Андагы ризыклардан авыз иткәч, йөзе ачылып, күңелләре күтәрелеп китте. Бар ризыклары тәмле, нәрсә алыйм дисәң шул бар: итлесе кирәкме, төрледән-төрле балык ризыклары дисеңме, камыр ризыклары, салатлармы... Хәләл булгач, рәхәтләнеп ашадык, балаларга дип тә бер сумка пәрәмәч җыйдым әле... "Апа, кирәк кешегә заказга бәлешен дә, пирогын да, пилмәнен дә пешереп бирәбез", – диләр андагы кызлар. Анысы да бик рәхәт, Коръән мәҗлесләре үткәргәндә, әзер ризыкларын кайнар килеш күтәреп кайтырга була шул. Шушында ук намаз укыр өчен аерым бүлмә дә бар икән, анысын белеп тә сөенеп туя алмадык. Мондагы базада эшләгәннәргә дә, әйбер алырга килгәннәргә дә ишегә ачык, җан рәхәте инде. Хәзерге заманага Аллага шөкер дип кенә торасы, сайлау мөмкинлеге бар, ризыкларыбыз хәләл булып, тәнебезгә, җаныбызга шифа бирсен берүк.

**Рәсимә апагыз, Минзәлә районы.**

*Балалар өчен*

# Изге иман

*(Гакыйдә)*

**Алып баручы:** Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әссәләмүгаләйкүм үә рахмәәтуллааһи үә бәракәтүһ. (Сезгә Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәтләре булсын). Аллаһ Тәгалә "Әнгам" сүрәсенең 53 аятендә: "...Нигъмәтнең иң зурысы – Ислам динедер, шөкер итүнең иң зурысы – Ислам динен дөрес тотудыр", – ди. Бу фани дөньяда һәм Ахирәттә дә адәм балаларын бәхетле итәр өчен Аллаһ Раббыбыз барлык кешелеккә ислам динен биргән. (Әл-Гыймран сүрәсе, 19 нчы аять: "Хак дин, Аллаһ дине – Исламдыр").

**Бала:**
*Динең нигезе өчәү:*
*Ислам, Иман, Ихсан.*
*Тик Аллаһыга буйсыну –*
*Ислам шул, шикләнмә моңа.*
*Йөрәк һәм сүздә ышану –*
*Сүз бара иман турында.*
*Ихсан – эштә, уйларыңда,*
*Сүзләреңдә эчкерсезлек.*
*Аллаһыбыз белеп тора,*
*Барысын да күреп тора.*

**Бала:**
*Мөселман булырга теләсәң,*
*Хезмәт итү зарур Аллаһыга,*
*Ызгыш-бәхәсләрсез яшәү*
*Һәм тик Аңа буйсынырга.*
*Кушканнарын үтәргә гел,*
*Тыйганыннан тыелырга.*
*Ислам шундый гүзәл дин ул,*
*Бирелгән бар халыкларга.*

**А.б.** «Аллаһның илчесе, саләллаһу галәйһи вәсәллəм әйткән: "Ислам биш баганага нигезләнә: Аллаһтан башка илаһ юклыгына һәм Мөхәммәд (с.г.в.) – Аның илчесе булуына шәһадәтлек китерүгә, намаз укуга, зәкәт түләүгә, Рамазан аенда ураза тотуга һәм Хаҗ кылуга".

**Бала:**
*Исламның биш терәге бар –*
*Әзер тор үтәргә барын.*
*Аллаһ риза булсын синнән,*
*Ачсын Җәннәт капкаларын.*
*Үзең сана дустым: шәһадәт,*
*Биш тапкыр намаз көнгә.*
*Онытма зәкәт, уразаны.*
*Булдыра алсаң әгәр дә –*
*Хаҗ кылырга Мәккәгә.*

**"Нәниләргә дин нигезләре"китабы буенча китапханәче Сөмбелә Фәхертдинова әзерләде.**


**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.
**Тиражы 1280.**

**Индексы 54149**

* * *


Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.


* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**28 ноябрь 16 сәг.**
**фактта 28 ноябрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**